КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 16 июль г.Казань № 574

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморан-думында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстен-лекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 10 февраль, 66 нчы карары белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморанду-мында билгеләнгән өстенлекле юнәлеш-ләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 10 февраль, 66 нчы карары белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 24 – 26 пунктчалар өстәргә:

«24) «Тозлы суда сыр җитештерү» («Агросила-Молоко» ҖЧҖ, Яр Чаллы шәһәре);

25) «Ярым каты сыр җитештерү» («Агросила-Молоко» ҖЧҖ, Яр Чаллы шәһәре);

26) «Татарстан Республикасы Минзәлә районының Степановка торак пунктында 2400 башка исәпләнгән сөт-товар фермасын» төзү («Август-Минзәлә» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы).»;

1.5 пунктта:

2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) «Бетон өчен өстәмәләр җитештерү буенча модификацияләнгән үзәк» («Полипласт-Казан» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы).»;

1.15 пунктта:

19 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 34 – 36 пунктчалар өстәргә:

«34) «Транснефть – Прикамье» акционерлык җәмгыятенең торба үткәргеч транспорты объектларын реконструкцияләү, модернизацияләү» («Транснефть – Прикамье» АҖ, Татарстан Республикасы);

35) «Татарстан Республикасының Казан шәһәрендә халыкара спорт үстерү үзәге (хай-дайвингны кертеп)» (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Казан шәһәре);

36) «Юстиция кварталы» объектларын төзү» (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Казан шәһәре).»;

2 бүлектә:

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) «Кабатлана торган ысул белән 1 елга 60 мең тоннага кадәр куәтле дивинилстироль синтетик каучук җитештерү(«Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, Түбән Кама шәһәре).»;

2.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) «Kazan Palace by Tasigo (1 чират)» («Полистрой Иншаат Тааххют Санайи Ве Тиджарет Аноним Ширкети» АҖ, Казан шәһәре).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин